РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2021 с. Сарманово № 76

**«2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы, Россия Федерациясе Президентының 2012елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 08 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләренең һәм башка телләрнең кулланылышын саклап калу, өйрәнү, үстерү һәм арттыру өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.«2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.

2.Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бюджет формалаштырганда Программаны гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бүлеп бирүне каракарга тәкъдим итәргә.

3.Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә һәм мәгариф бүлегенә программаны үтәү кысаларында чаралар планын расларга тәкъдим итәргә.

4.Әлеге карарны Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Ф. А. Вәлиев

Сарман муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
« 01 » 03 2021 елның
76 номерлы карарына кушымта

**«2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»**
**муниципаль программасы**

## Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге;<br>Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| Программаны башкаручылар | Җирле үзидарә органнары, Сарман муниципаль районы муниципаль учреждениеләре һәм предприятиеләре (ОМС, МБУ, МУП МР)<br><br>Муниципаль район территориясендә физик һәм юридик затлар, хэйриячеләр |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | 1. Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм татар һәм рус телләрендә укытуның тулы системасын үстерү; Сарман муниципаль районыннан читтә татар телен өйрәнүгә һәм татар телендә укытуга ярдәм итү.<br>2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләренең дәүләт телләре буларак тигез хокуклы эшләвенә ярдәм итү.<br>3. Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни-методик ярдәм күрсәтү.<br>4. Сарман муниципаль районында яшәүче |

| | |
|---|---|
| | халыкларның телләрен саклау һәм үстерү.<br>5. Сарман муниципаль районында дәүләт телләренең һәм башка телләрнең социаль статусын күтәрү һәм популярлаштыру.<br>6. Сарман муниципаль районы белән Татарстан Республикасы районнары һәм Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче якташлар арасында районара һәм регионара хезмәттәшлек итү.<br>7. Районда этносларның тел мәсьәләсе торышын мониторинглау һәм анализлау. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары: | 2021-2022 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеп, финанслау күләме | 2021 ел-1775,0 мең сум<br>2022 ел - 1525,0 мең сум |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелгән ахыргы нәтиҗәләр | 2022 ел ахырына:<br>- Сарман муниципаль районында телләрнең оптималь эшчәнлеген тәэмин итү буенча гамәлләрне координацияләү максатларында тулы бер инфраструктура булдыру;<br>- Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка халыкларның телләрен һәрьяклап үстерү өчен матди-техник, мәгълүмат, укыту-методик базасын киңәйтү;<br>- норматив-хокукый актларны татар телендә чыгару 100 процент тәшкил итәчәк;<br>-Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- муниципаль учреждениеләр биналарында урнаштырылган ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларының гомуми саны 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- урам һәм юл күрсәткечләре, муниципаль учреждениеләр биналарының фасадларына куелган элмә такталарның ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән өлеше 100 процент тәшкил итәчәк; |

| | |
|---|---|
| | - хезмәт күрсәтү өлкәсе предприятиеләрендә ике дәүләт телендәге белешмә мәгълүмат 100 процент тәшкил итәчәк;<br>-мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә татар милләтеннән булган балаларны туган татар телендә укыту һәм тәрбияләү 60 процент тәшкил итәчәк;<br>- гомуми белем бирү учреждениеләрендә татар милләтеннән булган балаларны туган татар телендә укыту һәм тәрбияләү 75 процент тәшкил итәчәк;<br>- гомуми белем бирү учреждениеләрендә рус милләтеннән булган балаларны туган рус телендә укыту күләме 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында телләр мәсьәләсе торышын һәм Программаны гамәлгә ашыру барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырткан публикацияләр саны 30 берәмлек тәшкил итәчәк;<br>-район халкын милли мәдәни кыйммәтләргә җәлеп итү максатыннан үткәрелгән чараларда катнашучылар саны елына 50 мең кеше тәшкил итәчәк. |

## Норматив база

1. «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябреннән 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы.
2. Россия Федерациясенең «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 декабреннән 1642 номерлы карары.
3. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июленнән 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы
4. РФ Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе Дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабреннән 1666 номерлы Указы.
5. «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 25 октябреннән 794 номерлы Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары.
6. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабреннән 273-ФЗ номерлы Федераль законы.

7. Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының «Милләт җыены» киңәйтелгән утырышы карары белән 2020 елның 20 августында расланган «Татарлар: гамәлләр стратегиясе» үсеш концепциясе.

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, Программа буенча хәл ителәчәк мәсьәләләр

Әлеге Программа Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябреннән №1807-1 номерлы , «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» 2005 елның 1 июненнән 53-ФЗ номерлы Федераль Законнары, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабреннән 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе Дәүләт милли сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июленнән 1560-XII номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварыннан 1-ТРЗ номерлы Федераль Законнары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябреннән 794 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 3 июленнән ПУ-312 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Сарман муниципаль районының башка норматив-хокукый актлары нигезендә эшләнде һәм Дәүләт программасын гамәлгә ашыруга, Сарман муниципаль районында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, үстерү, өйрәнү өчен оптималь шартлар тудыруга юнәлтелде.

## II. Төп максат, максатларга ирешү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләре (индикаторлар), Программаның көтелгән ахыргы төп нәтиҗәләрен тасвирлау

Программа Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары нигезендә эшләнде, алар телләрнең үсеше һәм гармонияле үзара хезмәттәшлеген, Татарстан Республикасының Сарман муниципаль районында яшәүче халыклар вәкилләренең милли-тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклауны күздә тота.

Программаның максаты - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны гамәлгә ашыруны күздә тота:

1. Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм татар һәм рус телләрендә укытуның бөтен системасын үстерү; Сарман муниципаль районыннан читтә татар телен һәм татар телен өйрәнүгә ярдәм итү.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләренең дәүләт телләре буларак тулы хокуклы эшләвенә ярдәм итү.

Әлеге бурычны хәл итү кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең кулланылышы өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

3. Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни-методик ярдәм күрсәтү.

4. Сарман муниципаль районында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү.

Әлеге бурычны хәл итү кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар күпмәдәниятле белем бирү һәм тәрбия мохите булдыруга юнәлдерелгән.

5. Сарман муниципаль районында дәүләт һәм башка телләрнең социаль статусын күтәрү һәм популярлаштыру.

Әлеге бурычны хәл итү кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар күпмәдәниятле җәмгыятьтә тел һәм мәдәни мохит булдыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

6. Сарман муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы районнары һәм Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче якташлар арасында регионара һәм районара хезмәттәшлек.

7. Татарстан Республикасында этник - тел ситуациясенә мониторинг һәм анализ.

Программаның максаты һәм бурычлары Россия Федерациясе халыкларының мәдәниятләрен һәм телләрен саклау һәм үстерү, аларның рухи бердәмлеген ныгыту, милли азчылыкларның хокукларын тәэмин итү, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында яшәүче халыкларның этномәдәни үзенчәлеген саклау, мәгариф өлкәсендә инновацияләрне стимуллаштыру, талантлы яшьләргә ярдәм итү, иң яхшы укытучыларны һәм укучыларны бүләкләү, заманча мәгариф технологияләрен кертү өлешендә Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган “2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе” максатларына һәм бурычларына, туры килә.

Программа чаралары программа бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында телләрне саклау һәм үстерүнең барлык төп аспектларын үз эченә ала.

Программаның максаты һәм бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чараларны финанслау аңа кушымта аша тәкъдим ителгән.

## III. «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасын ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чараларын финанслау аңа кушымта аша тәкъдим ителә.

Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты хисабына 3300 мең сум тәшкил итә, шул исәптән 2021 елда-1775 мең сум, 2022 елда-1525 мең сум.;

Программада программа чараларын гамәлгә ашыру өчен бюджеттан тыш акчалар (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчалары) һәм авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты төп башкаручыларның үзара бәйләнешен, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм башкаручыларның чараларны нәтиҗәле куллануын контрольдә тотуны тәэмин итә. Программаның чаралары башкаручыларның ведомство программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны башкаручылар район башкарма комитетына квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нә кадәр аның үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

## V. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге тасвирламасы

Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе-белем дәрәҗәсен, этнотел компетенциясен арттыру, телләрнең эшчәнлеге өлкәсен киңәйтү, тел компетенцияләренең, квалификацияләренең ролен, мәгариф, хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәрләренең профессиональлеген арттыру, мәдәни һәм этнотел төрлелеген саклау, толерантлыкны һәм милләтара татулыкны арттыру.

Программада каралган чараларны гамәлгә ашыру рухи байлыкны арттыруга, халык өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында яшәүче халыкларның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен популярлаштыручы мәгърифәтчелек чараларының һәркем өчен ачык булуына; Татарстан Республикасы дәүләт телләренең функциональлеген арттыруга; тиешле инфраструктура булдыруга ярдәм итәчәк, ул Татарстан Республикасы тел законнарын гамәлгә ашыру буенча башкаручыларның эшен координацияләргә һәм оптимальләштерергә ярдәм итәчәк.

Программа чараларын гамәлгә ашыру төрле типтагы һәм дәрәҗәдәге белем бирү учреждениеләренең белем бирү һәм тәрбия эшчәнлеген

үстерергә, педагогның социаль статусын күтәрергә, мәгариф системасын һәм хезмәт күрсәтү өлкәсен халыкның этнотелле ихтыяҗларына якынайтырга, халыкның туган телләрен өйрәнүдә һәм үстерүдә конституцион хокукларын якларга ярдәм итәчәк.

Программа сәяси, икътисадый, социаль һәм этномәдәни өлкәләрдә һәм мәгълүмат киңлекләрендә, шулай ук район һәм татар теле мәгариф системасында Татарстан Республикасының дәүләт һәм башка телләре эшчәнлеген чагылдыручы микъдари күрсәткечләрне арттыруны, Сарман районында яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклауны һәм үстерүне, дәүләт һәм башка телләрнең Сарман районында социаль статусын һәм абруен күтәрүне күздә тота.

Программаның нәтиҗәлелеге гамәлләрне билгеләнгән вакытта башкару дәрәҗәсе буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләренең агымдагы хисаплылык материаллары файдаланыла.

Рухи һәм интеллектуаль өлкә үсеше белән бәйле программаның үзенчәлеген исәпкә алып, икътисади нәтиҗәне билгеләү күздә тотылмый.

## VI. Регионара хезмәттәшлек

Регионара һәм районара хезмәттәшлек Россия Федерациясе субъектларында һәм Татарстан Республикасында Сарман муниципаль районында туып-үскән якташлар җәмгыятьләре эшчәнлеге, социаль-икътисади хезмәттәшлек кысаларында башка республика һәм район чараларында оештырыла.

## VI. Программаны гамәлгә ашыру срогы

Программа 2021-2022 елларда тормышка ашырыла. Программаны гамәлгә ашыру этапларга бүленми.

“2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасына кушымта

**«2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы нәтиҗәләрен бәяләүнең максаты һәм бурычлары, индикаторлары һәм аның чараларын финанслау**

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Үлчәү берәмлеге | Бәяләү индикаторының әһәмияте | | МР бюджет акчалары хисабына финанслау-мең сум | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2021 | 2022 |
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 10 | 11 |
| **Максат 1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру** | | | | | | **775,0** | **525,0** |
| **Бурыч 1.1. Татар һәм рус телләренең Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак тигез хокуклы эшчәнлегенә ярдәм итү;** | | | | | | **50,0** | **50,0** |
| 1.1.1. Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән урам һәм юл күрсәткечләре, муниципаль учреждениеләр биналарында урнаштырылган элмәакталары, тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чаралары өлеше | ОМС МР<br>МБУ МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | 50,0 | 50,0 |
| 1.1.2. Татарстан Республикасының документлар әйләнешен ике | ОМС МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дәүләт телендә алып бару | МБУ МР | | | | | эшчәнлек кысаларында | |
| 1.1.3. Норматив хокукый актларны ике дәүләт телендә бастырып чыгару (рус һәм татар телләрендә). | ОМС МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| **Бурыч 1.2. Сарман муниципаль районында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни-методик ярдәм күрсәтү.** | | | | | | **75,0** | **75,00** |
| 1.2.1. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклау һәм үстерү эшен иң яхшы оештыруга мәктәпкәчә мәгариф оешмалары тәрбиячеләре арасында ел саен конкурс үткәрү | ОО МР | 2021-2022 | кеше | 30 | 30 | 15,0 | 15,0 |
| 1.2.2. Региональ әһәмияттәге фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү | ОО МР | 2021-2022 | берәмлек | 2 | 2 | 60,0 | 60,0 |
| **Бурыч 1.3. Сарман муниципаль районында дәүләт һәм башка телләрнең социаль статусын күтәрү һәм популярлаштыру.** | | | | | | **650,0** | **400,0** |
| 1.3.1.Район территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе предприятиеләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүмат булу, ике дәүләт телендә халыкка хезмәт күрсәтү | ОМС МР, башка затлар | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.3.2.Татар һәм рус телләрендә массакүләм мәгълүмат чаралары өлеше, чагыштырма | ОМС МР | 2021-2022 | % | 50/ 50 | 50/ 50 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.3.3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында тел торышы һәм Программаны гамәлгә ашыру барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр саны | ОМС МР МБУ МР | 2021-2022 | берәмлек | 25 | 30 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.3.4. Тарихи вакыйгаларга һәм (яки) туган телне саклауга һәм үстерүгә өлеш керткән күренекле эшлеклеләрне, шул исәптән Сарман районында туып-үскән райондашларны хөрмәтләүгә багышланган юбилей чараларын үткәрү. | ОМС МР МБУ МР | 2021-2022 | берәмлек | 15 | 5 | 350,0 | 100,0 |
| 1.3.5. Белем бирү һәм башка тематик чаралар үткәрү | ОК МР ОО МР | 2021-2022 | берәмлек | 12 | 12 | 300,0 | 300,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Бурыч 1.4. Сарман муниципаль районында телләрнең оптималь эшләвен тәэмин итү буенча гамәлләрне координацияләү максатыннан, тулы бер инфраструктура булдыру һәм аның эшләвен тәэмин итү** | **ОМС МР МБУ МР** | **2021-2022** | **%** | **100** | **100** | **Агымдагы эшчәнлек кысаларында** | |
| 1.4.1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару | ОМС МР МБУ МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында татар милләте балаларын татар телендә укыту һәм тәрбияләүне колачлау өлеше | ОО МР МБУ МР | 2021-2022 | % | 55 | 60 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.3. Гомуми белем бирү оешмаларында татар милләтле балаларын туган телдә укыту һәм тәрбияләү белән тәэмин итү өлеше | ОО МР МБУ МР | 2021-2022 | % | 70 | 75 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.4. Гомуми белем бирү оешмаларында рус милләтендәге балаларны туган телдә укыту белән тәэмин итү өлеше | ОО МР МБУ МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.5. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе халыклары телләрендә районның гомумфайдалану китапханәләре фондының һәркем файдалана алырлык булуы | ОК МР | 2021-2022 | % | 100 | 100 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.6. Район халкын милли мәдәниятләр кыйммәтләренә җәлеп итү максатыннан үткәрелгән чараларда катнашучылар саны | ОК МР ОО МР | 2021-2022 | елына мең кеше | 50 | 50 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| 1.4.7. Сарман муниципаль районында Татарстан Республикасы халыклары дәүләт телләрен һәм телләрен һәрьяклап үстерү өчен матди-техник, мәгълүмат һәм укыту-методика базасын үстерү | ОК МР ОО МР | 2021-2022 | | | | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| **Максат 2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү.** | | | | | | **1000,0** | **1000,0** |
| **Бурыч 2.1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында этно-тел ситуациягә мониторинг һәм анализ** | ОК МР ОО МР | 2021-2022 | елга бер тапкыр | 1 | 1 | **Агымдагы эшчәнлек кысаларында** | |
| **Бурыч 2.2. Сарман муниципаль районы һәм Татарстан** | | | | | | **1000,0** | **1000,0** |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Республикасыннан читтә яшәүче якташлар арасында регионара һәм районара хезмәттәшлек, татар телен саклау һәм үстерү** | | | | | | | |
| 2.2.1. Россия Федерациясе субъектларында һәм район территориясендә татарлар күпләп яши торган милли бәйрәмнәрне, шул исәптән «Сабантуй» милли бәйрәмен оештыру һәм уздыру, Сарман районында туып-үскән якташлар җәмгыяте эшендә катнашу. | ОК МР<br>ОО МР | 2021-2022 | чаралар саны. | 3 | 4 | 670 | 700 |
| 2.2.2. Төрле категория гражданнарны җәлеп итеп, регионара һәм районара чараларны (конкурслар, фестивальләр, конференцияләр, семинарлар һ.б.) оештыру һәм үткәрү, яисә аларда башка регионнарда яисә районнарда катнашу. | ОК МР<br>ОО МР | 2021-2022 | чаралар саны. | 10 | 12 | 330 | 300 |
| **Бурыч 2.3. Сарман муниципаль районыннан читтә татар телен укытуга һәм татар телендә укытуга ярдәм итү.** | | | | | | **Агымдагы эшчәнлек кысаларында** | |
| 2.3.1. Россия Федерациясе регионнарында һәм Татарстан Республикасы шәһәрләрендә яшәүче балалар өчен тематик, шул исәптән онлайн-чаралар уздыру. | ОК МР<br>ОО МР | 2021-2022 | чаралар саны. | 4 | 4 | Агымдагы эшчәнлек кысаларында | |
| **ПРОГРАММА БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | | | | | | **1775,0** | **1525,0** |